КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 19 март г.Казань № б-453

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Урман кодексының 51, 53 – $53^8$, 83, 96 һәм $98^2$ статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында» 2020 ел, 7 октябрь, 1614 нче карары нигезендә һәм урман фондында, шулай ук Татарстан Республикасы милкендәге урман кишәрлекләрендә һәм урман утыртмаларында урман янгыннарын сүндерү буенча вәкаләтләрне үтәү, кызыксынучы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының урман янгыннарын сүндергәндә үзара хезмәттәшлек итү дәрәҗәсен арттыру максатларында:

1. Бу боерыкка теркәлгән 2026 елда Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны һәм торак пунктларын янгыннардан саклау эшен оештыру чаралары планын расларга.

2. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына:

кызыксынучы республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарының башкарма комитетлары белән берлектә, урманнарда янгын чыгуны профилактикалауга һәм аларга каршы көрәшүгә юнәлдерелгән оештыру-техник чаралар комплексын үткәрүне тәэмин итәргә;

урман янгыннарын сүндерү буенча башкарыла торган эшләрнең, шулай ук күрсәтелгән хезмәтләрнең күләмнәре дөреслеген һәм аларның сыйфатын, янгыннарга каршы чаралар үткәрүне һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы учреждениеләрнең урман янгыннарын сүндерү станцияләренең янгын чыгу куркынычы сезонына әзерлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга;

урман массивларында урнашкан табигый һәм ясалма сулыклардан янгын сүндерү техникасы белән су алу өчен билгеләнгән мәйданчыклар оештырырга, шулай ук аларга транспорт белән тоткарлыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итәргә;

законнар белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы учреждениеләрнең, шулай ук

урман фонды җирләрендә эшләр башкаручы оешмаларның һәм урман кишәрлекләрен арендага алучыларның урман янгыннарын сүндерүгә әзерлеген ачыклау буенча тикшерүләр оештырырга һәм гамәлгә ашырырга;

урман фондын махсуслаштырылган оешма белән авиация ярдәмендә бюджеттан бүлеп бирелгән акча исәбеннән саклауны тәэмин итәргә;

урман янгыннарын башланган стадиядә ачыклау, локальләштерү һәм бетерү буенча кичектергесез чаралар күрүне тәэмин итәргә;

урман янгыннарын сүндерү планнары нигезендә федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән урман фонды җирләрендә чыккан урман янгыннарын сүндерүне оештырырга;

урманчылыклар территорияләрендә урман янгыннарын сүндерү буенча расланган планнар нигезендә коммерция оешмалары һәм коммерциягә карамаган оешмалар хезмәткәрләрен, аларның янгын сүндерү техникасын һәм транспорт чараларын, шулай ук гражданнарны урман янгыннарын сүндерүгә җәлеп итәргә;

урман фондында, шулай ук башка категорияләрдәге җирләрдә урнашкан урман кишәрлекләрендә һәм урман утыртмаларында урман янгыннары исәбен алып барырга;

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенең Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы белән мәгълүмати хезмәттәшлек турындагы килешүе нигезендә көн саен Татарстан Республикасының барлык категорияләрдәге җирләрендә урман янгыннары турында Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә белешмә бирергә;

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасы белән чиктәш Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары белән урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә үзара хезмәттәшлек турындагы килешүләре нигезендә барлык категорияләрдәге җирләрдә урман янгыннары чыгу, аларны локальләштерү һәм бетерү турында мәгълүмат алмашуны тәэмин итәргә;

урман янгыннарын сүндерүгә федераль бюджеттан субвенцияләр алу өчен документларны үз вакытында әзерләүне, рәсмиләштерүне һәм кертүне тәэмин итәргә;

федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән урман янгыннарын сүндерү чыгымнарын формалаштыру һәм аларның исәбен алып бару тәртибе буенча Урман хуҗалыгы федераль агентлыгы тәкъдимнамәләре нигезендә бу максатлар өчен җәлеп ителә торган оешмалар белән үз вакытында исәп-хисаплар ясарга;

зыянның күләмен билгеләү, урман янгыннары чыгуда гаепле затларны ачыклау һәм аларны законнар белән билгеләнгән җаваплылыкка тарту, шулай ук янгын чыгу аркасында салынган зыянны каплау буенча кирәкле чараларны үз вакытында башкаруны оештырырга.

3. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына урман янгыннары биләгән территорияләрдә хокук тәртибен һәм куркынычсызлыкны тәэмин итүне, гражданнар һәм автотранспорт йөрүне чикләүне һәм урман янгыннары чыгуда

гаепле затларны ачыклауны тәэмин итүне оештыруда Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына, Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсенә, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына законнар белән билгеләнгән тәртиптә ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

4. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән берлектә, түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

язгы-җәйге чорда янгыннар санын киметүгә юнәлдерелгән янгын чыгуга каршы профилактика чаралары комплексын эшләүне;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә, массакүләм мәгълүмат чараларында торак пунктларының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча үткәрелә торган чараларны һәм проблемалы мәсьәләләрне, янгыннар белән бәйле хәл-торышны кичектергесез яктыртуны, шулай ук халыкка язгы-җәйге чорда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында мәгълүмат бирүне оештыруны;

зур масштаблы янгыннарны сүндерү һәм һәлакәттән коткару эшләрен үткәрү буенча терәк пунктларының куелган бурычларны үтәүгә әзерлеген тәэмин итүне;

гражданнар җыеннарын үткәрүдә һәм янгын куркынычсызлыгы чараларын пропагандалауда катнашуны;

барлыкка килә торган хәлне исәпкә алып, кирәк булганда көчләрнең һәм чараларның (шул исәптән объектларны саклау буенча) урынын алыштыруны;

барлыкка килә торган хәлне исәпкә алып, резервтагы янгын сүндерү техникасын хәрби исәпкә кую буенча чаралар күрүне, янгын сүндерә торган төп автомобильләрне (хәрби исәптәге һәм резервтагы) янгын сүндерү өчен билгеләнгән кораллар (шапылдаткычлар) белән комплектлап бетерүне.

5. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына, барлык милек рәвешләрендәге авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре белән берлектә:

урман һәм торф массивлары янындагы авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә язгы кыр һәм урып-җыю эшләрен башкарганда урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре һәм Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләре үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашырырга;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә корыган үләннәрне, камылларны һәм ашлык суктырганнан соң калган калдыкларны, шулай ук агач-куак үсемлекләрен яндыруга юл куймау буенча чаралар күрергә;

урман массивлары янындагы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре эшли торган территорияләрне чиста тотарга, аларны чүп-чардан һәм корыган агач-куаклардан үз вакытында чистартырга;

гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгән очракта, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең янгын сүндерә торган күчмә техникасы белән ирекле янгын сүндерү формированиеләренең тәүлек буе кизү торуын оештырырга;

су алу өчен янгын сүндерү техникасы белән ясалма сулыкларга һәм су этем манарасыннан су алу җайланмаларына керү юлларын яраклы хәлдә тотарга.

6. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары буендагы юл кырыйларын, откосларны һәм бүлеп бирелгән полосаларны чүп-чардан, кирәкмәгән үлән һәм агач-куак үсемлекләрдән системалы рәвештә чистартып торуны тәэмин итәргә.

7. «Волго-Вятскуправтодор» федераль казна учреждениесенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

урман массивлары аша үтә торган федераль әһәмияттәге автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосаларын, төзекләндерү элементларын янгыннардан саклау буенча кирәкле чаралар күрүне;

федераль әһәмияттәге автомобиль юллары буендагы юл кырыйларын, откосларны һәм бүлеп бирелгән полосаларны чүп-чардан, кирәкмәгән үлән һәм агач-куак үсемлекләреннән системалы рәвештә чистартып торуны тәэмин итүне.

8. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

100гә кадәр кеше исәбеннән чыгып, мобилизацияләнгән хәрби хезмәткәрләрне урнаштыру һәм тукландыру мөмкинлеген, шулай ук аларны кирәкле эш кораллары белән һәм урман янгыны чыккан урынга кадәр алып бару өчен транспорт чаралары белән тәэмин итүне күздә тотуны;

профилактика төркемнәренең урман фонды җирләрендә урнашкан һәм урман фонды җирләре белән турыдан-туры тоташкан торак пунктларын тикшерүен оештыруны;

табигый янгыннар чыгу куркынычы янаганда һәм килеп чыкканда Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасы звеноларының көндәлек идарә органнары эшчәнлеген яраштыруны гамәлгә ашыруны;

урман янгыннары ялкыны торак пунктларына һәм гражданнарның җәйге ял итү объектларына күчкән очракларда, халыкны эвакуацияләүне тәэмин итүне, шул ук вакытта техниканың кирәкле санда булуын, эвакуация урыннарын, эвакуацияләнгәннәрне ашатуны һәм аларга медицина ярдәме күрсәтү мөмкинлеген алдан ук кайгыртып куюны;

урман фонды җирләре белән турыдан-туры тоташкан торак пунктларын һәм икътисад объектларын саклау өчен минералланган полосалар булдыру эшен оештыруны;

урман фонды җирләрендә урнашкан һәм урман фонды җирләре белән турыдан-туры тоташкан торак пунктларында, дача кооперативларында һәм бакчачылык җәмгыятьләрендә төнлә патруль торуны оештыруны;

урман янгыннарына каршы көрәшү һәм урман (торф) янгыннарын сүндерүгә халыкны, эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне, шулай ук әлеге оешмаларның янгын сүндерү техникасын һәм транспорт чараларын җәлеп итү эшләрен башкарганда оешмаларның гамәлләрен яраштыруны тәэмин итү буенча чаралар күрүне;

урман янгыннарына каршы көрәшүгә җәлеп ителә торган затларны күчеп йөрү чаралары, туклану һәм медицина ярдәме белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтүне;

урман фонды җирләрендә урнашкан торак пунктларын телефон элемтәсе, янгын сүндерү өчен билгеләнгән су белән тәэмин итү, табигый һәм ясалма сулыкларда пирслар ясау, су этем манараларын янгын сүндерү автомобильләре белән су алу җайланмалары белән җиһазландыру, урман массивлары белән тоташкан торак пунктлары һәм икътисад объектлары чикләре буйлап минералланган полосалар ясау буенча чаралар күрүне;

шәһәр һәм авыл торак пунктлары җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын янгыннардан саклауны яхшырту буенча чаралар күрүне;

2026 елның 10 маена кадәр Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасы көчләре һәм чараларының урман янгыннары чыгуга бәйле гадәттән тыш хәлләргә әзерлеген тикшерү буенча укуларын һәм күнекмә ясауларын үткәрүне;

2026 елгы янгын чыгу куркынычы сезонында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән муниципаль хокукый актлар кабул итүне;

янгын чыгу куркынычы сезонына әзерлек чаралары планын раслауны;

превентив характердагы гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм бетерү чараларын үткәрүгә финанс чаралары резервын булдыруны;

янгын сүндерү өчен билгеләнгән ясалма су белән тәэмин итү чыганаклары җайланмаларына көн саен мониторинг ясауны тәэмин итүне;

социаль хезмәтләр, попечительлек советлары, полиция, янгынга каршы дәүләт хезмәте хезмәткәрләрен, янгыннан саклау буенча ирекле хезмәт, торак-коммуналь оешмалар әгъзаларын һәм җирле үзидарә органнары вәкилләрен составка кертеп, профилактика төркемнәрен төзүне;

чүп-чар, корыган үлән яндыруны кисәтү максатларында, профилактика төркемнәренең торак пунктларына тикшерүләр үткәрүен оештыруны;

янгын сүндерү техникасы белән янгыннан саклау буенча ирекле һәм муниципаль формированиеләр әгъзаларының тәүлек буе кизү торуын оештыру чаралары комплексын гамәлгә ашыруны;

зур күләмле урман һәм торф янгыннарын сүндергәндә файдалану өчен полиэтилен торбаларны кичектергесез алып килү мөмкинлеген күздә тотуны.

9. Урман янында территориясе булган, аннан файдалана һәм (яки) аның белән эш итә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, оешмаларга, иҗтимагый берләшмәләргә, индивидуаль эшмәкәрләргә, вазыйфаи затларга, Россия Федерациясе гражданнарына, чит ил гражданнарына, гражданлыгы булмаган затларга кар катламы эрегән көннән тотрыклы яңгырлы көзге һава торышы урнашканга яки кар катламы барлыкка килгәнгә кадәр урманнан алып кимендә 10 метр киңлектәге полоса буенда корыган үлән үсемлекләреннән, ашлык суктырганнан соң калган калдыкларны, чыбык-чабактан, киселгән агач

калдыкларыннан, чүп-чардан һәм башка яна торган материаллардан чистартуны тәэмин итәргә яисә урманны кимендә 1,4 метр киңлектәге янгынга каршы минераллаштырылган полоса яки башка янгынга каршы киртә белән бүлеп алырга тәкъдим итәргә.

10. Үз ведомствосында урман фонды территориясендә яки урман фонды белән тоташкан җирләрдә урнашкан оешмалары (шул исәптән балалар савыктыру лагерьлары) булган республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләренә янгынга каршы профилактика чаралары комплексын үткәрүне һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләре үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

11. Төрле милек рәвешләрендәге оешмалар җитәкчеләренә урман янгыннарын сүндерү планнары (оператив (мобилизация) планнар) нигезендә урман янгыннарын сүндерү өчен көчләр һәм чаралар бүлеп бирүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

12. «Түбән Кама» милли паркы», «Идел-Кама дәүләт табигый биосфера тыюлыгы» федераль дәүләт бюджет учреждениеләре, Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Мари урманчылыгы – Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Урман хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесе филиалы, Горький тимер юлындагы «Россия Федерациясе Тимер юл транспортының ведомство саклау хезмәте» федераль дәүләт предприятиесе филиалының Казан отряды җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

югарыда күрсәтелгән учреждениеләргә беркетелгән территорияләрдә янгынга каршы профилактика чаралары комплексын үз вакытында үтәүне тәэмин итүне;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләр чикләрендә янгын чыгу очраклары турында Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына оператив мәгълүмат бирүне.

13. «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыятенә янгынга каршы профилактика чаралары комплексын үз вакытында үтәүне, шул исәптән линия объектларының (электр тапшыру линияләренең) саклау зоналарында урман буйларын чүпләнүдән һәм чүп-чардан чистартуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

14. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 21 март, б-599 нчы боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

15. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 19 март, 453 нче
карары белән расланды

2026 елда Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны һәм торак пунктларын янгыннардан саклау эшләрен оештыру чаралары планы

| Т/с | Чара исеме | Чараны үтәү срогы | Башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Урман янгыннарын сүндерү станцияләренең янгын чыгу куркынычы сезонына әзерлеген тәэмин итү чаралары комплексын башкару | апрель | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |
| 2. | «Татарстан Республикасының урман хуҗалыгын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасында каралган урманнарны янгыннардан саклауга бәйле чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |
| 3. | Министрлыклар, ведомстволар, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләре һәм шактый зур мәйданлы урманнардан файдаланучы арендаторлар катнашында урманнарны янгыннардан саклау мәсьәләсе буенча видеоконференция режимында киңәшмә үткәрү | март – апрель | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |
| 4. | Урман фонды җирләрен (җир өсте һәм авиация зоналарын) патрульләү маршрутларын эшләү һәм графикларын раслау | апрель | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |
| 5. | Урман янгыннарын сүндерү җитәкчеләрен, урман янгыннарын сүндерү станцияләре хезмәткәрләрен һәм Татарстан | апрель | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының ведомство буйсынуындагы дәүләт бюджет учреждениеләре белгечләрен укытуны оештыру һәм уздыру | | |
| 6. | Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче көчләре һәм чараларының Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының ведомство буйсынуындагы учреждениеләре һәм Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә караган янгынга каршы дәүләт хезмәте белән үзара хезмәттәшлеген үзләштерү буенча укулар үткәрү | апрель – май | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре – урман хуҗалыклары (алга таба – «Урман хуҗалыгы» ДБУ), «Урман янгыннарын сүндерү үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – «Урман янгыннарын сүндерү үзәге» ДБУ), Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре – урманчылыклар (алга таба – «Урманчылык» ДКУ) |
| 7. | Урман массивлары янындагы территорияләрдә гражданнар күпләп ял итү урыннарын патрульләүне оештыру | май – сентябрь | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) |
| 8. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының янгын чыгу куркынычы югары дәрәҗәдә булганда халыкның урманга керү мөмкинлеген чикләү турындагы боерыкларын үз вакытында әзерләүне тәэмин итү | апрель – октябрь | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |
| 9. | Урман янгыннарын космостан мониторинглау мәгълүматын кабул итүне һәм анализлауны тәэмин итү | апрель – октябрь | «Урман янгыннарын сүндерү үзәге» ДБУ, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | |
| 10. | Урман массивларында яки алар янәшәсендә, шул исәптән Татарстан Республикасының Мари Республикасы һәм Удмуртия Республикасы территорияләре белән булган чикләрендә урнашкан торак пунктлар янында минералланган полосаларны яңарту һәм яңаларын булдыру эшләрен үткәрү | апрель – май | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, муниципаль берәмлекләрнең башкарма хакимият органнары (килешү буенча) |
| 11. | Махсуслаштырылган диспетчерлык хезмәтен булдыру һәм аның тәүлек буе эшләвен тәэмин итү | апрель – октябрь | «Урман янгыннарын сүндерү үзәге» ДБУ |
| 12. | Янгынга каршы кисәтү, профилактика чаралары комплексын уздыруны һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итү | апрель – октябрь | урман фонды җирләрендә һәм урман фонды янындагы җирләрдә урнашкан ведомство карамагындагы оешмалары булган республика башкарма хакимият органнары, шул исәптән балалар сәламәтләндерү лагерьлары |
| 13. | Кешеләр бик еш була торган урыннарда, беренче чиратта, торак пунктларыннан чыга торган урыннардагы автомобиль юллары һәм тимер юллар буйларында янгынга каршы тематикага бәйле билбордлар һәм баннерлар сериясен урнаштыруны тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, «Урман хуҗалыгы» ДБУ |
| 14. | Урманнарда һәм торак пунктларда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча үткәрелә торган чараларны һәм аларны тәэмин итүдә катлаулы мәсьәләләрне, янгыннар белән бәйле оператив хәлләрне массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештыру, шулай ук көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы чаралары (Халыкка мәгълүмат бирү һәм хәбәр итү буенча гомумроссия комплекслы системасының системаларын куллануны кертеп) турында халыкка мәгълүмат бирү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы |
| 15. | Татарстан Республикасы территориясендәге урман фонды җирләрендә һәм башка категорияләр җирләрендә урнашкан торф | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, «Урман- |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | сазлыклары биләгән мәйданнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын эшләү | | чылык» ДКУ, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары (килешү буенча) |
| 16. | Көн саен урманнарны җирдән патрульләү юлы белән урманнарда һәм урман янгыннарында янгын куркынычлылыгын мониторинглауны тәэмин итү, урман янгыннары чыгуны кисәтү максатларында янгынга каршы пропаганда һәм башка профилактика чараларын уздыру | апрель – октябрь | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, «Урман хуҗалыгы» ДБУ, «Урманчылык» ДКУ |
| 17. | Ведомство буйсынуындагы бюджет учреждениеләрендә янгын чыгу куркынычы сезонына ягулык-майлау материаллары резервын булдыруны тәэмин итү | апрель | «Урман хуҗалыгы» ДБУ, «Урман янгыннарын сүндерү үзәге» ДБУ |
| 18. | Урман массивлары янындагы урман фонды территорияләрен, торак пунктларны төзекләндерүне тәэмин итү | апрель – октябрь | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары (килешү буенча) |
| 19. | Урман фонды җирләрендә урнашкан торф сазлыклары биләгән мәйданнар янында су белән тәэмин итү чыганакларын (янгын сүндерү өчен билгеләнгән сулыклар) булдыру (булмаган очракта) буенча өстәмә чаралар комплексын гамәлгә ашыру, аларга килү юлын һәм су алу мөмкинлеген тәэмин итү | апрель | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, «Урман хуҗалыгы» ДБУ |
| 20. | Урман хуҗалыгы эшләре комплексын башкаруга (шул исәптән урманнарны янгыннан саклау), урманнарны авиация белән саклауга һәм яклауга контракт төзү хокукына аукцион үткәрү | апрель | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |

---